Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә якынча җаваплар (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 6 нчы сыйныф

Максималь балл – 38.

I. Теоретик биремнәр. (8 балл)

1. Чәчмә формада язылган нинди халык авыз иҗаты жанрларын билгели аласыз? Санап чыгыгыз. (5 балл)

Әкият, миф, мәзәк, риваять, легенда.

2. Түбәндә аталган жанрларның кайсылары халык авыз иҗатына карый. (3 балл)

А) **мәкаль**
Б) **җыр**
В) шигырь
Г) **мәзәк**
Д) хикәя

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (15 балл)

1. “Җил иясе җил чыгара” мифында һәм Г.Гыйльмановның “Җил иясе, Кәмлүч һәм Кәриз” әсәрендә Җил иясе образларына чагыштырма характеристика бирегез. (10 балл).

2. “Җил иясе, Кәмлүч һәм Кәриз” әсәрендә Г.Гыйльманов ни өчен Кәмлүч һәм Кәриз образларына мөрәҗәгать иткән дип уйлыйсыз? Алар аша укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

Кешенең акылы, зирәклеге һәм һөнәрле булуы, бердәмлеге теләә нинди авырлыкны җиңәргә, зур максатларга ирешергә мөмкинлек бирә h.б.

III. Иҗади эш. (15 балл)

Елга, тау, кар, яңгыр, Су иясе образларын кертеп, кечкенә генә миф иҗат итеп карагыз.